**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 25 октябрендәге 4478 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы карары белән расланган**
**«Центр» территориясен планлаштыру проектына**
**Сара Садыйкова һәм Салих Сәйдәшев урамнары киселешендә**
**үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023 һәм 2024 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 июнендәге 2453 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 11 июнендәге 2478 номерлы карары белән расланган «Центр» территориясен планлаштыру проектына Сара Садыйкова һәм Салих Сәйдәшев урамнары киселешендә үзгәрешләр әзерләү турында»гы карарын исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслап, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы карары белән расланган «Центр» территориясен планлаштыру проектына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 21 августындагы 2979 номерлы, 2021 елның 7 маендагы 1143 номерлы, 2022 елның 23 маендагы 1501 номерлы, 2022 елның

29 июлендәге 2452 номерлы, 2022 елның 17 августындагы 2775 номерлы, 2022 елның 6 сентябрендәге 2928 номерлы, 2022 елның 19 сентябрендәге 3133 номерлы, 2022 елның 27 сентябрендәге 3295 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 4520 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге 4607 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 4767 номерлы, 2023 елның 13 апрелендәге 1076 номерлы, 2023 елның 7 ноябрендәге 3363 номерлы 2023 елның 25 декабрендәге 4308 номерлы, 2024 елның 26 гыйнварындагы 262 номерлы, 2024 елның 29 гыйнварындагы 274 номерлы, 2024 елның 25 мартындагы 1073 номерлы, 2024 елның 25 мартындагы 1076 номерлы, 2024 елның 16 апрелендәге 1578 номерлы, 2024 елның 2 июлендәге 2825 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Сара Садыйкова һәм Салих Сәйдәшев урамнары киселешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы карары белән расланган «Центр» территориясен планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә 6 номерлы кушымта) (хезмәт урынында файдалана торган материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 25 октябрендәге
4478 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы карары белән расланган**
**«Центр» территориясен планлаштыру проектына**
**Сара Садыйкова һәм Салих Сәйдәшев урамнары киселешендә**
**кертелә торган үзгәрешләр**

1. Төбәк дәрәҗәсендәге һәм җирле әһәмияткә ия капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән территориядәге төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турындагы нигезләмәдә:

1.1. түбәндәге эчтәлектәге 2.1.26 пункт белән тулыландырырга:

«2.1.26. 254 кварталда урнашкан 16:50:011721:578 кадастр номерлы җир кишәрлеге өчен (шулай ук югарыда атап үтелгән кишәрлек белән кадастр эшләре башкарылган очракта) җир кишәрлеге чикләрендә төзелешнең (торак фондының) максималь тыгызлыгы 13,81 мең кв.м/га тәшкил итә»;

1.2. 2.5.5.3 пунктта «48 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе» сүзләрен «47 блоклы комплектлы трансформатор подстанциясе» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Кызыл линияләрне, социаль-мәдәни билгеләнештәге һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрен күрсәтеп, планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 1 һәм 2 номерлы кушымталар нигезендә бирергә.


3. Кызыл линияләрне, юллар, урамнар, тыкрыклар, элемтә линияләре, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларын билгеләнә торган линияләрне күрсәтеп, планлаштыру проекты сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләргә 3 һәм 4 номерлы кушымталар нигезендә бирергә.

4. Борылыш нокталары координаталары белән кызыл линияләрне күрсәтеп, планлаштыру проекты сызымы фрагментын, әлеге үзгәрешләргә 6 номерлы кушымта нигезендә билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырып, әлеге үзгәрешләргә 5 номерлы кушымта нигезендә бирергә.

________________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы
карары белән расланган «Центр»
территориясен планлаштыру проектына
кертелә торган үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа Проекта планировки с указанием красных линий, границ зон планируемого размещения объектов социально-культурного и коммунально-бытового назначения, объектов капитального строительства местного значения




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ


- Красные линии улично-дорожной сети установленные
- Граница зоны планируемого размещения объектов капитального строительства

Зоны планируемого размещения объектов капитального строительства

- 3 — малоэтажной жилой застройки (до четырех этажей, включая мансардный)
- 1 — порядковый номер зоны размещения
- 1 — вид зоны размещения ОКС
- 1,00 — площадь зоны размещения (га)
- 1.1 — код вида разрешенного использования
- 10 — максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м.)
- 10 — максимальная этажность

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы
карары белән расланган «Центр»
территориясен планлаштыру проектына
кертелә торган үзгәрешләргә
2 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа Проекта планировки с указанием красных линий, границ зон планируемого размещения объектов социально-культурного и коммунально-бытового назначения, объектов капитального строительства местного значения




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

Красные линии улично-дорожной сети установленные

Красные линии территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) устанавливаемые

Граница зоны планируемого размещения объектов капитального строительства

Зоны размещения объектов капитального строительства

20 — зеленых насаждений общего пользования

1 — порядковый номер зоны размещения

1 — вид зоны размещения ОКС

1,00 — площадь зоны размещения (га)


1.1 — код вида разрешенного использования

10 — максимальная общая площадь жилищного фонда (тыс.кв.м.)

10 — максимальная этажность

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы
карары белән расланган «Центр»
территориясен планлаштыру проектына
кертелә торган үзгәрешләргә
3 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа Проекта планировки с указанием красных линий, линий, обозначающих дороги, улицы, проезды, линии связи, объектов инженерной и транспортной инфраструктур





УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

Красные линии улично-дорожной сети установленные

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы
карары белән расланган «Центр»
территориясен планлаштыру проектына
кертелә торган үзгәрешләргә
4 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа Проекта планировки с указанием красных линий, линий, обозначающих дороги, улицы, проезды, линии связи, объектов инженерной и транспортной инфраструктур




УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

- Красные линии улично-дорожной сети установленные
- Красные линии территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети) устанавливаемые
- Т — Ориентировочное расположение проектируемой ТП, РТП, БКТП

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2015 елның 24 июнендәге 2478 номерлы
карары белән расланган «Центр»
территориясен планлаштыру проектына
кертелә торган үзгәрешләргә
5 номерлы кушымта

Фрагмент чертежа Проекта планировки с указанием красных линий с координатами поворотных точек

